**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 17 август № 566

г. Казань

Триатлон буенча IRONSTAR 113 KAZAN 2016 Россия Кубогы этабын үткәргәндә су объектыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 нче пункты нигезендә, Казан шәһәренең Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча IRONSTAR 113 KAZAN 2016 Россия Кубогы этабын үткәргәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елның 26 августында 14.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр һәм 2016 елның 27 августында 5 сәгать 30 минуттан 17 сәгать 30 минутка кадәр Казансу елгасы участогында Казан шәһәренең Кремль транспорт дамбасыннан «Миллениум» күперенә кадәр кечкенә суднолар, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт өчен каралган суднолар, шул исәптән гидроцикллар, байдаркалар, ишкәкле көймәләр куллануны тыярга.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән судноларны куллануга тыю Казан шәһәренең Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча IRONSTAR 113 KAZAN 2016 Россия Кубогы этабын әзерләү һәм үткәрү өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, әлеге карарның 1 нче пунктында кертелгән тыюны саклау максатларында, күрсәтелгән су объекты участогында кизү торуны тәэмин итәргә.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр

министрлыгы белән берлектә, әлеге карарның 1 нче пунктында кертелгән тыюны саклау максатларында, күрсәтелгән су объекты участогында кизү торуны тәэмин итүне;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына кертелә торган тыю турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештыруны, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков